**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Урта Ушма поселогында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

17 ноябрь, 2020 ел

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең урта Ушма торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. Ушминка елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау өчен җыелган гражданнарның үзара салым акчасын 40425 (кырык мең дүрт йөз егерме биш) сум күләмендә урта Ушма Бистәсе юлына вак таш сатып алу өчен файдаланырга.

2. Җыенның нәтиҗәләрен Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә http://pravo.tatarstan, Балтач муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //baltasi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы С. А. Мухин